КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 ноябрь г.Казань № 968

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында «Победа авылына килү юлы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен юридик зат милкендә (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) булган, кушымтада күрсәтелгән 64 104 253 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килә торган 28 149 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләре милекчесе тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Победа авылына килү автомобиль юлын төзү  объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын раслау турында» 2022 елның 04 февралендәге 56 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проектлау нигезендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрү;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр күләмен билгеләүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 18 ноябрь , 968 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 16:21:000000:7 | Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы | 56 438 489 | 1 492 | «Август-Кайбицы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 16:21:000000:112 | Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы | 7 665 764 | 26 657 | |
| Барлыгы | | 64 104 253 | 28 149 | |

_______________________________________